Ютазы районы Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбендә оештырылган “Бәхетле балачак” театр түгәрәгенең 2022-2023нче уку елына отчёт

Башлангыч сыйныф укучыларын аралашырга өйрәтү, орфоэпик күнекмәләрне камилләштерү, чыгыш ясау осталыгын үстерү, татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру зарурлыгын күздә тотып, театр түгәрәге программасы төзелде һәм дәрестән соң эшчәнлек оештырылды. Театр сәнгатенә караган материаллар, балалар өчен сәхнәләштерелгән әсәрләр, шигырьләр, милли фольклор бәйрәмнәре программаның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шулай ук спектакльләр, видеофильмнар карау, күренекле артистлар белән очрашулар укучыларның театр сәнгате буенча осталыкларын үстерүдә зур урын алып торды.

Театр түгәрәгендәге шөгыльләр аша укучыларның сөйләм телләрен, иҗади активлыгын үстерү өчен шартлар булдырыла. Театр түгәрәге шөгыльләрендә сәнгатьле сөйләм осталыгына өйрәтү сәнгать осталары үрнәгендә, әдәби әсәрләр нигезендә һәм практик күнегүләр белән ныгытылып алып барыла.

Театр түгәрәге программасы 70 сәгатькә (атнага 2,5 сәгать исәбеннән) 1 елга төзелде.

**Сентябрь аенда эшләгән мероприятиелар:**

-түгәрәкнең эш планы белән таныштырылды

- инструктаң үткәрелде

- сәхнә теленең тормыштагы гади телдән аермасы аңлатылды

- татар халык җыры “Талы-талы” ның сүзләрен һәм музыкасын өйрәнеп сәхнәләштерү.

**Октябрь аенда эшләгән мероприятиелар:**

- Нәҗия Гыймадиеваның “Елак батыр” әсәрен сәхнәләштерү
- Балалар һәм яшьүсмерләр театр Республика фестиваленең муниципаль этабында катнашып “Туган телне саклау өчен” дигән номинацияны яуладык. Приказ №351/1 , 11 октябрьдан 2022 ел.

**Ноябрь аенда эшләгән мероприялар:**

- Кәрәкәшле авыл клубында әниләр көне бәйрәменә багышланган концертта Нәҗия Гыймадиеваның “Елак Батыр” спектакле белән чыгыш ясадык.

- Мәктәптә “Сөмбелә” бәйрәмендә “Яшелчәләр бәхәсләшүе” дигән скетч куйдык.

**Декабрь аенда эшләгән мероприялар:**

- Киенү һәм бизәнү осталыгы белән танышу
- Татар халык уеннарын уйнау: “Йөзек”, “Йомгак”, “Чишмә”
- Яңа ел турнда җырлар өйрәнү.

Гыйнвар аенда клубка кереп спектакльнең видеоязмасын тошердек. Аны монтажлап конкурсларда катнашу өчен җибәрергә әзерләдек. Планыбыз “Нәүрүз” бәйрәменә әзерләнү. Бәйрәмдә спектакль белән чыгыш ясау. Шулай ук балаларны татар халкының драматурглары белән таныштыру. Г.Тукай туган көнгә багышланган мероприятияда чыгыш ясау.

Җитәкче: Нәгыймова Илсөяр Сәет кызы.
31.05.2023